# Һади Такташ (1901-1931)



**Мин яралдым серле моңнарым белән бар дөньяны еглатырга. Әйе, миндә көчле Байроннар җаны.**

**Һади Такташ**

# Тамбов губернасы. Спас өязе. Сыркыды авылы.
# (хәзерге Мордва республикасының Тарбеево районы)




# Такташ туган изге йорт.



# Әтисе һәм әнисе



*Һади Такташның әнисе Шәмсениса*



*Һади Такташның әтисе Хәйрулла*

# Такташлар гаиләсендәге 9 баланың 6сы исән-сау үсеп житә.


Һади Такташның апасы Фатыйма



Һади Такташның олы абыйсы Хафиз



Һади Такташ



**Һади Такташның энесе Габидулла** **Һади Такташның сеңлесе Хәнифә** **Һади Такташның сеңлесе Мәрзия**





*Һади Такташның сеңлесе Хәнифә*



# Һади Такташның балачагы белән бәйле истәлекләр.

Менә Һадинең 5-6 яшьлек чагы. Башка малайлар белән бергә Хәсәннәр бакчасына кереп,кыярларын тунап чыкканнар. Зуррак балалар йөгереп качалар. Хәсән абзый Һадины эләктереп ала. Бер колагыннан тотып, икенчнсе белән балага суккалый,кычкырып тирги. Тавышны ишетеп, Шәмсенисә апа урамга йөгереп чыга: “Хәсән абзый , ни өчен кыйныйсың?”-ди. “Әнә үзе әйтсен”,-дип, Хәсән абзый өенә таба китеп бара. “Улым, ник еламыйсың, ичмасам, еласаң, кыйнаудан туктар иде”,ди әнисе. “Еласам, малайлар ишетерләр дә аннары мине беркайчан да разбуйникка алмаслар”,-дип җавап бирә Һади. Әнисе “разбуйникның” корсагына кысып тоткан күлмәк итәген ачып карый. “И балам, бу нәни генә кыярларны ничек җәлләми өзден соң, борыннарыннан чәчәкләре дә төшмәгән бит әле!” Шул чагында Һади, малайлар ишетү ихтималын онытып, кычкырып елап җибәрә. “Хәзер нәрсәгә елыйсың инде?”-дип сорый әнисе. “Бик нәниләр бит әле-е-е, хәзер үсәлмиләр бит инде-е-е”,-дип такмаклый Һади.

Кечкенәдән ул әдәбият укырга һәвәс малай булып үсә. Кулына эләккән беренче китапны, журналны - йотлыгып укып бара. Әнисе Шәмсениса апа, улының омтылышларына куанып, китап алып улын шатландырыр өчен чәченә үреп йөри торган кадерле тәнкәләренә кадәр берәм-берәм сата.

Һади кечкенәдән җырлар, такмаклар чыгаруга һәвәс булган. Җиде яшендә чакта ук ул  авылдашы- дусты Мокамайның йомырка урлап тотылуы уңае белән такмак чыгара. “Соңга таба авыл җырчысы булып киттем. Минем җырларны әле дә Сыркыуында җырлыйлар бугай” дип искә ала шагыйрь соңыннан.

Соңрак, йомышчы малай булып йөргәндә, төрле хуҗаларның каралган керләрен, каралган идәннәрен юып көн утә, Бохара кибетчеләренең хезмәтчесе булып тора. Булачак шагыйрь кешене рухи һәм физик изүне үз күзләре белән күрә. Шуңа да аның: “Мин үткәннәрнең караңгы тарихын беләм идем, шуның өчен мин үткәннәргә бунт белән чыктым” ,- дип язуы очраклы түгел.

# Пешлә чоры
## (1911-1913)

-“Күңел җимешләре”исемле кулъязма җыентыгын төзи.



Һадины Сыркыдыдан 30 километр ераклыктагы Пешлә авылына укытырга озаталар.

Үз вакытында якын – тирәдә иң атаклы мәдрәсәләрдән саналган Пешлә мәдрәсәсенә күчеп , Һади анда өч кыш укый. Мәдрәсәдә аз - маз хисап, җәгрәфия, тарих укытыла. Һади Пешләдә укыганада укуда зирәклеге белән нык аерыла, укытучылар аны бик яраталар. Ул чакта чыга торган “Вакыт”, “Йолдыз”, “Ялт-йолт” газеталары һәм журналларын, мөгәллимнәрдән эләккән әдәбият китапларын укый. Кышларын Пешләдә укып, җәен авылда эшләп вакытын үткәрә.

# Бохара чоры
# (1914-1917)



Үз көнен үзе күрсен дип, атасы аны туганрак тиешле сәүдәгәргә  ияртеп Бохарага озата.Ул анда бер байның манафактура кибетендә приказчик ярдәмчесе  булып эшли. Аның күңелен матурлык илаһилык күрке - әдәбият үзенә тарта.
Бохарада Һади белемен күтәрергә омтыла, телләр өйрәнә, күп укый, спектакльләр куюда катнаша.

Түбәндәге әсәрләре монда иҗат ителә:

1.”Газраилләр”(1916)
2.”Караңгы төннәрдә (1916)
3. “Төркстан сахраларында (1917)-беренче шигыре (1918 нче елның 21 нче гыйнваренда “Олуг Төркстан”газетасында басыла)

# Сыркыды чоры (1918)



-1918 нче елда Такташ Урта Азиядән йөреп кайта, мәктәптә үзенең беренче шигырьләрен укый.
Бу хәбәр бөтен авылга тарала.

Бу чорда язылган әсәрләре:
-“Күктән сөрелгәннәр” балладысы
-“Үтерелгән пигамбәр” балладысы

# Оренбург чоры (1919-1920)



Әдәби эш белән чиксез кызыксыну һәм белемен арттырырга теләве 1919 нчы елның көзендә Оренбургка китәргә мәҗбүр итә. Ул “Юксыллар сүзе “ газетасында җаваплы секретарь булып эшкә

**Оренбургта язылган әсәрләр:**

**1.”Ачлык патша(1920)**

**2.”Антым” (1920)**

**3. “ Айның нурлары арасында (1920)**

**4.(Җил сөйли..)**

# Ташкент чоры
# (1921-1922)



Идел –Җаек буйларында хөкем сөргән ачлык аны “ипиле” Ташкентка алып китә. Бу вакытта ул анда университетта әдәбият укыта. “ Белем йорты” журналында җаваплы сәркәтип булып эшли.

Мәскәү чоры(1922)

1922 нче елны Такташ берничә ай Мәскәүдә яши.

Һади Такташ Маяковский шигырьләр укуын карарга йөри. Аның кебек үз шигырьләрен укырга өйрәнә.



# Казан чоры
# (1922-1931)



- 1922 нче елның көзендә ул Татарстанның башкаласы Казанга бөтенләйгә күчеп килә.Казанга килгәч, берникадәр вакыт татар театрында суфлер булып эшли, аннары “Чаян”, “Октябрь яшьләре”, “ Авыл яшьләре” журналында һәм 1926 нчы елның октябреннән 1929 нчы елның мартына кадәр “Азат хатын” жуналы редакциясендә җаваплы секретарь вазифаларын башкара. 1929 нчы елның яңадан “Чаян” журналы редакциясенә кайта һәм гомеренең ахырына кадәр шунда эшли.

**Һ. Такташның гаиләсе белән дә танышып үтик.**

**-Һади Такташ тормышында өч Гөлчирә була. Берсе-шагыйрь белән бергә “Азат хатын” журналында эшләгән Гөлчирә Гафурова. Икенчесе – Гөлчирә Хәмзина – шагыйрнең беренче хатыны, өченчесе – Гөлчирә Мансурова – шагыйрнең икенче хатыны.**


# Такташ гаиләсе.

Беренче хатыны Гөлчирә Хәмзина белән.



Һади Такташ беренче хатыны Гөлчирә Хәмзина белән. (Л.Гайнанова тупланмасыннан)

# Улы Рафаил




Һ.Такташ улы Рафаил белән Кара диңгездә. (А.Такташ тупланмасыннан)

# Икенче хатыны Гөлчирә һәм улы Аван.



Һ.Такташның икенче хатыны Гөлчирә Такташева-Мансурова




Һ.Такташның улы Аван


# Такташ уллары:

- Рафаил -дәрәҗәле академик, профессор, сәнгать белгече. Ташкента яши. Ике югары уку йорты тәмамлаган. Байтак кына милләт рәссамнарының иҗаты турында монографиялар язган. Үзе өчен шигырьләр дә иҗат иткән.
- Аван – фотога тәшерү белән мавыккан. Озак еллар гәзитнең урыннарда йөречү фотографы булып эшли.
- Такташның өч оныгы бар: Искәндәр-укытучы, Йолдыз-табиб-хирург, Гузәл-журналист.

**Һади Такташ 1931 елның 8 декабрендә вакытсыз вафат була. Аның гәүдәсе Казан шәһәренең М. Горький исемендәге Үзәк ял паркы янында туганнар каберлегендә җирләнгән.**

# Һади Такташның 100 еллыгына чыккан истәлекләр китабы




Һади Такташ


КАРАБОРЫННЫҢ
ДУСТЫ


ХАДИ ТАКТАШ
ДРУГ
ЧЕРНОНОСОГО


Хади Такташ
ДРУГ
ЧЕРНОМОРДОГО


Һади Такташ
КАРАБОРЫННЫҢ
ДУСТЫ


Һади Такташ
ТӘҮФЫЙКЛЫ
ПЕСИ


Һади Такташ
ТӘҮФЫЙКЛЫ
ПЕСИ


ХАДИ ТАКТАШ
ДРУГ
ЧЕРНОМОРДОГО


Һади Такташ
КАРАБОРЫННЫҢ
ДУСТЫ

# Һади Такташ.
# “Мокамай” поэмасы.

1. Поэманы укып чыгу.
2. Язылу  тарихын ачыклау.
3. Әсәрнең темасын билгеләү.
4. Поэманың идеясен ачыклау.
5. Әсәрнең төп героен күрсәтү.
6. “Мокамай” әсәрендә образлар системасы аша эчтәлекне сөйләү.

# 1. Поэманы укып чыгу.

## Сүзлек өстендә эш.

табан — таба

менәлмәдең — менә алмадың

йолу — коткару, аралау, саклап

калу асылып — асылынып

күрәлдем - күрә алдым

# 2. Язылу тарихы.

Сәнгатьле уку.

99 нчы бит, 2 нче абзац.

Сәнгатьле уку.

100 нче бит, 2нче абзац.

# 3. Әсәрнең темасы

Тема – чикләп алынып, әсәрнең нигезенә салынган вакыйгалар һәм күренешләр берлеге, бөтенлеге.

Поэма нәрсә турында?

# 4. Поэмаың идеясе

Идея – тема куйган мәсъәләнең,сорауның җавабы ул.

Автор нәрсә әйтергә тели?

“Мокамай” поэмасында
дуслыкка тугрылык идеясе яңгырый.

# 5. Әсәрдәге геройларны һәм образларны системалаштыру. Моделен төзү.

## Лирик герой

***кичерешләре***

**Икеләнә, дулкынлана, борчыла, үкенә. Мокамайны аклауны бурычы итеп куя, аңа ант итә, туган җирен ярата, бала чагын сагына**

*портреты*

Сары чәчле

***сыйфатлары***

Нечкә күңелле, үзен җаваплы итеп тоя; әйтерсең авылдашларының мәрхәмәтсезлеге өчен гафу үтенә

## Мокамай

***кичерешләре***

**тасвирланмый**

***портреты***

**Кара чәчле, коңгырт кара күзле, кәкре аяклы дустым, җанкисәгем, бәгърем**

***сыйфатлары***

Яшәргә хаклы булуы; яшәргә теләү, оста булуы, яхшы күңелле, эш сөя

# Төп геройны билгеләгез

Әсәрнең исеме “Мокамай” булса да, актив кичерешләре, аңлаешлы эш-гамәлләре белән (хат яза, ант итә; мөнәсәбәтен белдерә, бәяли, үзе сөйли) төп рольне лири к герой уйный.

# 6. “Мокамай” әсәрендә образлар системасы.

| Образлар | мәгънәләре |
|---|---|
| **Тамбов урманнары: усак яфраклары; ак каеннар, карт имәннәр, камыш сабаклары** | **Туган җир** |
| **Әкияттәге ике бала** | Балачак дөньясына һәм үзләре танышып йөргән җирләргә үзләрен хуҗа итеп тою; ирек, хөрлек, эчкерсезлек |
| **Ак каен** | Тормыш юлы; лирик герой белән Мокамайның капма-каршы язмышларының гәүдәләнеше |
| **Талчыбык ашау** | Балачакта гафу ителә торган “гөнаһларның” җәзасын алу |
| **Кәсеп, һәлакәт, канлы пычак** | Ниндидер фаҗига булуга ишарә; шул фаҗиганең шаһитләре |
| **Хат** | Лирик герой бары тик Мокамай белән генә сөйләшә; аның өчен иң әһәмиятлесе – Мокамай белән аңлашу |
| **Ант** | Лирик герой Мокамай яклы, аны аклый; аңа һәм балачакка, дуслыкка тугры |
| **Чабаталар** | Ярлылык символы; шул ук вакытта эш сөю, осталыкның да гәүдәләнеше |

# Нәрсә ул дуслык?

***Ихтыяҗларның, карашларның, фикерләрнең уртаклыгы, үзара рухи якынлык, бер-береңне ихтирам итү хисләренә нигезләнгән мөнәсәбәт.***

# Дуслыкның
# нинди төрләрен беләсез

- Халыклар дуслыгы,
- Сәяси дуслык,
- Дәүләтләр арасындагы дуслык,
- Төрле милләт кешеләре арасындагы дуслык һ.б.

*Дусты күп кеше дала кебек киң, дусты юк кеше* *уч төбе генә.*

*Дусы күпне* *яу алмый.*

*Урманда куш тирәк,* *дөньяда дус кирәк.*

*Дустың үзеңнән* *яхшырак булсын.*

*Дустың үпкәләсә,* *дошман куаныр.*

*Дуслык ашаганда беленми,* *эшләгәндә беленә.*

*Дустын сакламаган* *дошманга эләгер.*

*Иске дусның берсе –* *яңа дусның йөзеге.*

*Дуслык – акчадан* *кыйммәтрәк.*

*Яңа дуслар тап,* *искесен ташлама.*

*Дуслар эзләмәгән кеше үзенә* *үзе дошман.*

# Әкият

Биек тау башындагы бер алачыкта көтүче яшәгән. Бервакыт яңгырлы бер төндә өч кеше аның ишеген шакыган.

- Минем өем бик бәләкәй, берегез генә керегез. Сез кемнәр соң? – дип сораган көтүче.
- Без – Дуслык, Бәхет һәм Байлык. Иң башлап кайсыбыз керүен үзең хәл ит...

<u>*Дуслар кирәк.*</u>

**Әби белән бабай әйтә:**
**“Имин булсын еллар, - ди, -**
**Чын дусларча аралашсын**
**Җир шарында илләр”, - ди.**
**Дусар булса, авыр түгел**
**Егылгач та торырга.**
**Дуслар белән генә мөмкин**
**Яхшы тормыш корырга.**
**Дуслар кирәк шул безгә дә**
**Өйдә, мәктәптә, тышта...**
**Кадерен белик дусларның.**
**Үпкәләтмик ялгыш та.**

***Римма Шәехова.***

# Синквейн:
# темасы – Дуслык.

1. 1 исем (кем? Нәрсә? Соравына җавап биргән 1 сүз)
2. 3 сыйфат (нинди? Кайсы? Сорауларына җавап биргән 3 сүз)
3. Фигыльләр (нишли? нишләде? нишләгән? һ. б. Сорауларына җавап биргән сүзләр)
4. 1 җөмлә белән үз мөнәсәбәтегезне белдерегез

# Һади Такташ ижаты буенча тест

# 1.Һ.Такташ ничәнче елда туа?

а)1901;

б)1902;

в)1903.

# 2.Ул кайсы авыл малае?

а)Кызылъяр;

б)Сыркыды;

в)Иске Кармәт.

# 3.Ул укырга- язарга кемнән өйрәнә?

а)әбисеннән;

б)апасыннан;

в)энисеннән.

**4.Үсә төшкәч,аны кайсы авыл мәдрәсәсенә укырга бирәләр?**

а)Кушлавыч;

б) Пешлә;

в)Кармәт.

# 5.1919 елның көзендә кая китә?

а)Казанга;

б)Уфага;

в)Оренбургка.

# 6. “Юксыллар сүзе” газетасында кем булып эшли?

а)сәркәтип;

б)мөхәррир;

в)мөдир.

# 7. Һ.Такташ ничәнче елда үлә?

а)1928;

б)1929;

в)1931.

Укытучы сүзе:

Такташ-минем иң яраткан шагыйрем. Гомерем буе мине аның шигырьләре озата йөрде. Рәдиф Гаташ сүзләре белән тәмамлыйсы килә дәресне.

Гомерем буе аның тавышын тыңлыйм,-
Үлмәс шагыйрь тавышын!
Ишетәм һаман да!
Гел ишетербез –
Йөрәкләр саңгырау булмаса:
Ул – безнең арада!

Дәрестәге активлыгыгыз, тырышлыгыгыз өчен бик зур рәхмәт!

Дәрес бетте,чыгарга мөмкин.

